**Исполнительный комитет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Башкарма комитеты**

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1061672003876 ИНН 1617003290 КПП 161701001
ЛБ 179150038 р/с 40204810500000370016 БИК 049205001

==========================================================

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 март 2018 ел №4

**Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 20 сентябрендәге 947 номерлы РФ Хөкүмәте карарына һәм янгынга каршы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендәге торак пунктларның тотрыклылыгын Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә гомуми файдаланудагы җирләрдә учаклар ягу, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне яндыру тыела, тик иң якын төзелешләргә кадәр ара 50 метрдан да ким булмаган урыннарда, җилсез вакытта, чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яки әйберләр яндыруны даими контрольдә тоту шартларында башкарыла.

2. Иске Чокалы торак пунктыннан 60 метр ераклыкта, көньяк – көнчыгыш юнәлештә, кызыл ак төстәге агач баганалар белән билгеләнгән җир участогының эчке чикләрендә урнашкан чүп-чарны, үләннәрне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки әйберләрне (алга таба текст буенча чүп-чарны яндыру), чокырның бер өлешен (карьер) яндыру урыны итеп билгеләргә.

3. Чүп яндыручыга, 2 нче пунктта күрсәтелгән урында, чүп яндыру вакытында үзе белән штык көрәге яки башка янгын сүндерү чаралары булырга киңәш ителә.

4. Әлеге карар республика, район һәм торак пункт территориясендә махсус янгынга каршы режим кертелгән чорда үз көчен җәелдерми.

5. Әлеге карар 2018 елның 01 маеннан үз көченә керә

6. Карарны авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә игълан итәргә.

**Иске Чокалы авыл җирлеге**
**Башлыгы:** Р.Р.Низамутдинов